Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

# Чаян



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ГЫЙНВАР* 2025 * КАЗАН

1




Теманың дәвамын 4-5 нче битләрдән карагыз

Алмаз ХӘМЗИН



# ЯҢА ЕЛ ТЕЛӘКЛӘРЕ

Матур да соң, якын да
Минем Туган илем!
Син тагын да матуррак
Була алыр идең!

Шулайлыкта көч-дәртең
Мөмкинлегең Синең.
Сөюеңне безгә дә,
Дим, күрсәтсәң идең...

Бер фикер – дүрт партия
Кая куа сине?..
Калдыр шуның тик берсен,
Йә, кирәкми – берсе!

Яңа елда шәп теләк
Телә, Илем, безгә!
Хәер, берни кирәкмәс,
Тимә, пенсиябезгә!

Хезмәт хаклары менә
Бераз артса ярый.
Уртача сиксән сигез мең,
Безгә унбиш – кырый...

Инде ничә еллар юк
Күңелдә тынычлык...
Яңа елда килер дип,
Җанны тынычлыйк!

Балалар, ниһаять, нык
Белемле булырлар.
Туган телләрендә дә
Күп китап укырлар!..

Шулай уйлыйсы килә
Яңа ел дәвамын.
Ике мең егерме биш
һәм гасыр елларын.

И Туган илем, Синдә
Үземне Зур кеше
Итеп тоясым килә.
Мин дә бит Сине сөеп,
Саклыйм яна-көя.

Тынлык бирмиләр, күрәм,
Талыйлар, даулыйлар.
Халкың уй-фикеренә
Салалар агулар.

Без булыйк һәрчак бердәм –
Кешеләр һәм дәүләт.
Яңа елдан шул кирәк –
Дуслыкта бит Куәт!

Валентин ДУБИНИН









# ШОМБАЙ болай диде...

Хөрмәтле «Чаян»! Ришвәтчелекне, гадәттә, чиновниклар белән бәйлиләр. Имеш, безнең бөтен бәлаләр шулар аркасында. Ә чынлыкта исә ул өлкәдә хезмәт куючыларның төп өлеше – мәсьәләләр хәл итүдән ерак торган, зур булмаган хезмәт хакына эшләүче намуслы кешеләр. Ә менә өстәрәк утыручылар арасында юньле кешеләр табу кыендыр...

**Г. ШӘМСИЕВ**

әлмәт

**– Ә мин риза түгел!** – диде Шомбай ага. – **Анда да намуслы түрәләр бар – алар ришвәтне үзләре бирүчеләрдән генә ала.**

Михаил МИХАЙЛОВ

## ЭЛЕК МОНЫ БАРЫСЫ ДА БЕЛӘ ИДЕ

Күршеләребездәге яшь гаилә белән таныштым. Сөйләшеп киттек. Сүз ара сүз чыгып, җайлап кына күршемнән сорап куйдым:

– Ә сез беләсезме һавада ничә процент кислород бар?

– Әйтә алмыйм!

– 21% чамасы – дим. – Элек моны барсы да белә иде…

Эштә практикага студент-айтишник килгән. Аннан сүз уңай сорыйм: ә син беләсеңме ундүртне ундүрткә тапкырлагач ничә була?

– Хәзер телефондагы калькуляторда чутлап алам, – ди.

– 196! Моны элек телдән белә иделәр…

Туганнарыма авылга кайттым. Өстәл артында сөйләшеп утырабыз. Кызыксынып кына туганымнан сорадым:

– Ә син Австралиянең башкаласы исемен беләсеңме?

– Әлбәттә, беләм – Вена!

– Вена – Австриянең башкаласы, Австралиянеке – Канберра! – дип төзәтеп әйттем аңа. – Элек география дәресләрендә моны ныгытып өйрәнә идек, шуңа күрә барыбыз да белдек…

Эштән ял алгач, Алтайга бардым. Бу юлы үземне тынычрак тотарга тырыштым. Безнең төркемдә тарих укытучысы бар иде мәктәптән. Сәяхәткә чыктык. Күркәм табигатькә сокланып йөрибез, тау һавасы шултикле саф, беркемнән берни сорамыйм. Шул вакыт тиктомалдан әлеге тарих укытучысы сорап куйды:


– Ә сез беләсезме РСДРПның "Искра" газетасының беренче саны ничәнче елда чыкканын?

– Искә дә кергәне юк! – дим.

– 1903 елны! Элек моны бөтенесе белә иде… – ди.

Чынлап та! Элек аны барысы да белә иде – бу сиңа кислород проценты да, Австралия башкаласы да түгел!

Анастасия ВАСИЛЬЕВА




Михаил ЛАРИЧЕВ



## ӘЛЕ КҮТӘРЕЛҮ, ӘЛЕ УТЫРУ

*(безнең ришвәтләр саннарда һәм фактларда)*

2024 елның башыннан Татарстанда 972 ришвәткә бәйле җинаять теркәлгән.

21 ришвәтче рәшәткә артына ябылган.

Ришвәтчеләрнең кылган гамәлләреннән күрелгән зыян 210 миллион сум тәшкил иткән, 550 миллион сумлык милек дәүләткә кайтарылган.

Гаепләнүчеләр арасында – 36 хокук саклау органнары хезмәткәрләре, Махсус хокук статус иясе – Эчке эшләр министрлыгы тикшерүчесе, адвокат, 5 сайлау комиссиясе әгъзасы, 1 депутат һәм 2 муниципаль берәмлек башлыгына карата 10 җинаять эше кузгатылган.

Уртача ришвәт күләме 2023 елдагы 263 меңнән 377 мең сумга кадәр үскән. Аның гомуми күләме шулай ук арткан һәм 223 миллион сум тәшкил иткән.

## 2024 ЕЛДАГЫ ИҢ ЗУР ЭШЛӘР


Район хакимияте башлыклары тоткарланган: Казанның Киров һәм Мәскәү районнары башлыгы Сергей Миронов, ТРның Тукай районы башлыгы Фаил Камаев һәм элеккеге мәгариф һәм фән министры, Актаныш районы башлыгы Энгель Фәттахов.

Федераль салым хезмәтенең 14 нче номерлы районара инспекциясенең элеккеге башлыгы Илнур Гыйләҗиевка карата 20,2 миллион сумлык ришвәт алган өчен эш кузгатылган.

Татарстанның ЗАГС идарәсенең элеккеге башлыгы Гөлшат Нигъмәтуллина 6,8 миллион сум зыян китерүдә гаепләнгән.

ТР Дәүләт төзелеш күзәтчелеге Төньяк-Көнбатыш территориаль инспекция органының элекеге башлыгы Илнур Сәмигуллинның ришвәт алу эше.

"Татарстан Республикасының гигиена һәм эпидемиология үзәге"нең баш табибы Елена Сизова 1,6 миллион сумлык мошенниклыкта гаепләнгән.




Алексей МАМАЕВ

## Натура белән аласызмы?

Безнең карикатурачылар күзаллавы буенча, ришвәт – ул кабинетларда зур агайлар кабул итеп утыра торган конвертта йә портфель эчендәге кәгазь акча. Без шулай уйларга ияләнгән. Тик чынбарлык бу беркатлы фикер йөртүдән күпкә катлаулырак булып чыга. Бүгенге коррупция – ул бюджет акчасын бүлү һәм откатлар, бизнестагы өлеш һәм офшордагы счётлар, "җылы урыннар" белән сәүдә итү, криптовалюта һәм башкалар. Ә менә урыннардагы, түбәнрәк дәрәҗәдәге ришвәт өстәгесеннән көтелмәгән борылышлар белән аерыла. Мондагы "бүләкләр" кайчагында кызык кына хәлләр китереп чыгара.

Мәсәлән, Иваново өлкәсендә ике юл инспекторы правасыз йөртүчедән ришвәтне... сыра һәм шашлык белән алганнар. 590 сумлык "тамак ялгау" өчен алар икәүләшеп гаепләнүчеләр эскәмиясенә эләккәннәр. Приморье краенда колония хезмәткәре бер тоткынга интернетка тоташтыру өчен роутер урнаштырырга рөхсәт биргән. Моның өчен ул шланг белән бергә самогон аппараты алган. Ә Тулада МЧС хезмәткәрләре, кафены тикшергәндә, тәртип бозуга юлыкканнар. Моңа күз йомарга 48 шешә алкоголь ярдәм иткән. Тик хәмер биш ел иректән мәхрүм калуга әверелгән. Ставропольедагы Нефтекум районында тикшерүче ике балигъ булмаган яшүсмерне иреккә чыгарырга ризалашкан. Моның өчен ул 55 мең сум һәм ике каз сораган. Калмыкиядәге очракта да йорт тереклеге ярдәмгә килгән. Анда призывник военкомга сарык тапшырырга маташкан. Ямалның элеккеге губернатор урынбасарының йортында исә башкарак манзара күзәтелгән. Коммерция оешмасы ярдәм йөзеннән анда бассейн урнаштырган. Әйтергә кирәк: ясалма дулкынлы ябык бассейн, ришвәтчелектә гаепләнеп, хәзер төрмәдә иза чигүче Актаныш районының элеккеге башлыгы Энгель Фәттахов йортында да табылган. Пермь краеның Кудымкар шәһәрендә юл эшчеләре ремонт вакытында кисәтү билгеләре куймаган булганнар. Юл инспекциясе хезмәткәре, беркетмә төземәү өчен, 20 тонна асфальт вагы таләп иткән. Асфальтны китергәннәр, ләкин моның өчен инспекторга карата җинаять эше кузгатылган. Әмма иң кызыклы очрак Байкал артында булган. Анда миграция законын бозган бизнесмен, җәзадан котылу максаты белән, Миграция хезмәтенең район бүлеге белән җитәкчелек итүче ханымга... 100 тимер юл шпаласы бүләк иткән.

Һәм ахырдан – милли колоритлы вакыйга. Мөслим районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рөстәм Ильясов Сабан туенда сәүдә палаткалары урнаштырган өчен, законсыз акча җыю оештырган. Нәтиҗәдә, чиновник 41 мең сумнан артык акча үзләштергән.

Бүген юләрләр һәм юллар турындагы билгеле гыйбарәне беркем дә шик астына куймый торгандыр. Юллар белән азмы-күпме шөгыльләнә башладылар, юләрләр һәрвакыт бөтен җирдә дә җитә иде, ә төп бәлага ришвәтчелек әверелде бугай. Монда инде юләрләр дә, тайгак юллар да җитәрлек. Кирәген сайлап ал гына...

**Тимур ФАТКУЛЛИН**







## ЧЫБЫРКЫ ДА, ПРӘННЕК ТӘ

Республика министрлыклары һәм ведомстволары арасында четереклелек рейтингы булса, беренчелек пальмасын, һичшиксез, Татарстанның Яшьләр эшләре министрлыгына бирергә мөмкин булыр иде. Һәм ул дөрес тә! Үзегез уйлап карагыз. Узган елның ноябрь ахырында министрлыкта министр урынбасары җитәкчелегендә җитди комиссия эшләде, аның көн тәртибендә: "Халыклар дуслыгы" фестивалендә министерствоның Казакъстанга командировкада булган өч хезмәткәре алган бүләкләр турындагы хәбәрнамәләрне карау; бүләкләрнең бәясен билгеләү һәм аларның киләчәк язмышы турында карар кабул итү. Югары комиссиянең игътибарын нинди бүләкләр җәлеп итте соң? Утырыш беркетмәсендә алар санап үткән логотиплы футболка, кәгазь календарь, блокнот һәм ашамлык прәннек. Бу бүләкләр комиссия әгъзаларына прәннексез генә тапшырылды. Беркетмәдә күрсәтелгәнчә, ашамлык прәннек "тиешчә файдаланылган".

Бүләкләрнең бәясен билгеләүче документлар булмаганлыктан, комиссия аларны бәяләү буенча эшне онлайн-кибетләрдән һәм маркетплейслардан бәяләрнең скриншотларын беркетеп, бер эшләнмә буенча, кимендә өч тәкъдим күләмендә шундый ук эшләнмәләргә бәяләрне карау, өйрәнү һәм анализлау нигезендә башкарды. Әмма "дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан ашалганга күрә" ашамлык прәннекләрнең бәясе генә табышмак булып кала. Бер комплектның уртача бәясе 1064 сум дип бәяләнә. Түрәләр өчен рөхсәт ителгән 3000 сумнан артмаганлыктан, фестиваль бүләкләрен министрлыкның өч хезмәткәренә калдырырга карар кылына.

Яшьләр министрлыгында яшь, алга киткән, акыллы егетләргә мондый «ришвәткә каршы» мәсьәләләрне җитди рәвештә хәл итү көлке икәнен бик яхшы аңлыйбыз. Әмма алар чыбыркы белән прәннек арасында – "коррупциягә каршы тору турында" федераль закон һәм тиешле урынга куллану өчен, кондитер товарлары арасында баланс тотарга мәҗбүрләр.

**Камил РУСТАМОВ**

## Ә аларда ничек?

Кытайда чиновникларны һәм аларның гаиләләрен, законсыз рәвештә баеп киткәч нәрсә көтәсен күрсеннәр өчен, даими рәвештә төрмәгә экскурсиягә йөртәләр. Программага шулай ук ришвәт өчен утыручы элеккеге чиновниклар белән очрашулар да кертелгән.

Кытайда уенчы ришвәтчеләрне һәлак итә торган компьютер уены уйлап чыгарганнар. Җиңеп чыкканнан соң каһарман ришвәтсез гүзәл дөньяга эләгә.

Прагада туристларга "Коррупция туры" – ришвәтчелектә эләккән чиновникларның затлы йортлары һәм виллалары буенча өч сәгатьлек экскурсия тәкъдим ителә. Бу – күңел ачу да, тәрбия дә һәм җәмгыять тарафыннан шелтәләү дә.

Һиндстанда ришвәтчеләр белән көрәшкә гадәти булмаган ысул ярдәмендә тотынганнар. Анда ришвәтне 50 рупиялек акчага бик охшаган "0" рупиялек банкнотлар белән бирә башлаганнар.

Казакъстанда да шулай ук, ләкин чын акча ярдәмендә көрәшәләр. Ришвәтчене кулыннан тоткан кеше ришвәт суммасының 10 процентын ала.

Көньяк Кореяда, әгәр ришвәт турындагы сигнал расланса, "хәбәрче" 1,7 миллионга кадәр премия ала.

Голландиядә тагын да ераграк киткәннәр: анда премияне "хәбәрчеләргә" генә түгел, ә намуслы чиновникларга да бирәләр.

Швециядә, законсыз баю теләге барлыкка килмәсен өчен, чиновникларның хезмәт хакын арттырганнар. Хәзер алар яхшы түләнә торган эшләрен югалтудан куркып торалар.

Австриядә мәктәп укучылары ришвәтчелеккә каршы юнәлтелгән семинарларда катнашалар. Алар анда ришвәтчелектән саклану ысулларын өйрәнәләр.

Ришвәтчеләрдән зыян күрүче мексикалылар ришвәтчелек сүзлеге булдырганнар. Авторлар анда ришвәтчелек белән бәйле төшенчәләргә шаян аңлатмалар биргәннәр. Мәсәлән, "Гадел хөкем – Мексикада булмаган иҗтимагый конструкция".

Боливиядәге Какьявири шәһәрендә яшәүчеләр ришвәтчелеккә баткан шәһәр башлыгын үзләренчә җәзаларга булганнар. Аны карнавалда хатынкыз киеме киеп катнашырга мәҗбүр иткәннәр. Халыкны көлдереп, чиновник шундый кыяфәттә шәһәр урамнары буенча узган.

Кайбер гарәп илләрендә иң җиңел юл белән киткәннәр: ришвәт алганда тотылган чиновникларны йә камчы белән кыйныйлар, йә аларның кулларын кисәләр икән.

# Абау!

## МИЛЛИОНЕРЛАР БӘЙГЕСЕ

Нигәдер Татарстанны курыкмас миллионерлар ягы дип саныйлар. Имештер, татарлар үзләре нефть өстендә утырган килеш үзәктән чемпионатлар, саммитлар һәм юбилейлар өчен акча суырталар. Ләкин күптән түгел үткәрелгән тикшерү бу татлы манзараны шик астына куйды. Татарстанлыларга бер миллион сум җыяр өчен армый-талмый 7 елдан артык тир түгеп эшләргә кирәк икән. Өстәвенә, республика халыкның зур сумма җыю мөмкинлеге буенча рейтингта 26 нчы урында гына булып чыккан. Беренче урыннарда Чукотка, Ямал-Ненец һәм Магадан өлкәләре, һәм, әлбәттә, Мәскәү алып тора икән.

## ЗӘГЫЙФЬ ДӘЛИЛ


Тукай районы башкарма комитетының элеккеге юристы эшкә урнашканда "билгесез кешедән" сатып алган ялган югары белем турындагы диплом күрсәткән. Бу ханым берничә суд эшендә катнашырга өлгергән, ә соңыннан үзе гаепләнүчеләр арасына эләккән. Үзен яклау йөзеннән, элек сатучы-кассир булып эшләгән ялган юрист диплом булмау белгечнең квалификациясенә бернинди дә тәэсир ясамый, дип белдергән. Ул үзе, мәсәлән, бу өлкәдә ун ел буе судларда бакчачылык оешмаларының вәкиле сыйфатында тәҗрибә туплаган икән. Әмма суд бу саллы дәлилне кабул итмәгән һәм юрист-кассирны 4 айга ирегеннән чикләгән.

## РАДИАТОР ВАКЫЙГАСЫ

Төн уртасында Менделеевскида бер ирнең фатирында җылыту торбасыннан кайнар су ага башлаган. Ул "Нептун+" идарәче компаниясенең авария хезмәтенә шалтыраткан, ләкин анда кыска гудоклар гына ишеткән. 260 (!) тапкыр шалтыратканнан соң, подвалга төшеп, җылы бирүне туктатырга үзенә туры килгән. Иртән ир кеше тагын 49 тапкыр шалтыраткан, һәм, ниһаять, "нептун"нардан җавап ишетү бәхетенә ирешкән. Аннан соң ул битатараф идарәчеләр өстеннән прокуратурага шикаять язган. Йокларга яратучы авария хезмәткәрләре өчен компания директорына 50 мең сум штраф түләргә һәм зыян күрүченең радиаторын алыштырырга туры килгән.

## АГЫП КИТКӘН АКЧА

Балык Бистәсе районында фермерлар гаиләсе үзләренең сөт фермасын киңәйтү өчен 28 миллион сумлык грант алган. Алынган акчага алар сыерлар санын арттырырга, 8 хезмәткәр кабул итәргә һәм еллык савымны 1170 тоннага җиткерергә тиеш булганнар. Әмма фермерларның планнары никтер үзгәргән. Акчаны алар үз мәнфәгатьләренә тотып бетергәннәр, ә булган малларны һәм техниканы сатканнар. Шулай итеп, алгарышсыз калган сөт эше җинаять эшенә әверелгән.



Владимир СОЛДАТОВ




Виктор ФЁДОРОВ



Константин ЧАХИРОВ

Юныс ЗӨБӘЕРОВ

# Мин синнән яхшымыни?

Мобильнигым шалтырады. Дөресрәге, «Ак чабата, ак оек»ны сузды. Малай куеп биргән иде телефонга, минем кулдан килми. Хәзерге яшьләр әллә нәрәләр белә. Үз улыңа тылсымчыга караган кебек карыйсың. Карасам, таныш номер түгел. Билгесез номер булса, мобильниктан җавап бирмәскә кушсалар да, кирәкле кнопканы бастым.

– Алё, – мин әйтәм.

Бу фәлән кешеме? – ди бер бәндә. Тавышы официаль, бик җитди тавыш.

– Нәкъ өстенә бастыгыз, – дим. – Кайдан беләсез? Хәер, мине Татарстанда белмәгән кеше аздыр. Булуы да шикле. Балалар журналында мәктәптә укыганда бер шигыремне бастырганнар иде. Әле булса оныта алмый халык. Үлмәс шигырь булды.

– Сүз боткасы пешермик, – ди бу. – Мин банк хезмәткәре. Сезнең банкта яткан счетыгызда шикле җанлану. Акчагызга начар уйлы кешеләр хуҗа булмасын.

– ВТБ банкындамыни? – дим.

– Бүтән кайда булсын, – ди бу.

Үзем уйлыйм: «Телефон мошенниклары. Мине таларга уйлый». Ләкин курыкмыйм, ВТБ банкында да, башка банкта да минем бер тиен дә акчам юк. Алган пенсия икенче пенсиягә бетә дә куя. Үзем шуңа таң калам. Кая була бу акча? Канатлары юк, әллә кая очалар да китәләр. Болай акчаны юкка сарыф итмәскә дә тырышам. Коньякнең дә очсызлысын алам. Ләкин бу тырышлыгым бер нәтиҗә бирми. Пенсиягә бер-ике көн кала, манный боткасына күчәргә туры килә.

– Минем бит бу банктагы счётымда алты миллион сум гына, – димен. – Бу бит, урысчалатып әйтсәк, ерунда гына. Төкермим дә мин алты миллион сумга. Акчамыни бу? Мин андый гына югалту күргән кеше. "Т банкта" минем унтугыз миллион евро ята. Нацхим банкта ундүрт миллион доллар, минтранснефтегаз банкында сигез йөз мең фунт стерлинг. Шуннан үзегез уйлап карагыз. Акчамыни миңа бу агач алты миллион? Валютага тимәсеннәр зимагурлар. Күбәйде хәзер алар. Мин закон язсам, язып та куяр идем андый кемсәләргә. Телеграф баганаларына асып куярга, дип. Үлгәч, бер ел мәетләрен... Аһ, эт талагыры, телефонда акча бетте...

– Кергән шалтырату бушка бит, – ди бу.

– Минем икенче тариф шул, – димен. – гафут итәсез. Мең гафу. Ун мең гафу. Счётны бер айсыз тулылый алмыйм. Кесәдә җилләр уйный, Кара-ком чүллегендәге кебек коры кесәләр. Мин әле үземнең яхтада Канар утрауларына барып ятам. Өч балеринаны эләктереп. Һәрберсенә йөзәр мең доллар вәгъдә иттем. Хәзер кыйбатчылык, аена миллион кермәсә җан теләгәнчә яшәп булмый. Һәрнәрсәнең хакы арта, һаман өскә үрмәли. Икмәкнең буханкасы илле сум булсын инде. Ә? Акыртып талыйлар. Яшәргә мөмкинчелек юк. Утырып җыла.

Һәм телефонны өздем. Биш минуттан телефоным тагын шалтырады. Балансны тикшерсәм, мең сумга арткан баланс. «Шәп. Акчаның артыгы юк аның. Син нинди, мин дә шундый, нишләп әле мин синнән яхшырак булырга тиеш, киресенчә, күпкә начаррак», дип уйлыйм. Ниһаять тегеңә җавап бирдем.

– Бу тагын мин, – ди. – Банк хезмәткәре. Счётыгызда сәер активлык. Киңәш итәм: алты миллионыгызны икенче счётка күчерергә кирәк. Акчагыздан колак какмагыз. Заманасы шундый, карак каракка утырган да карак белән куа.


– Төкерәм мин алты миллионга. Бер авантюрада егерме дүрт миллион югалткан идем, эһ тә итмәдем. Минем өчен акча түгел, күрмәгәннәре шул булсын, – дидем.

Шуннан элемтәне өздем дә, тегенең номерын блокировать итеп куйдым. Үзем уйлыйм: «Тагын бер мошенник шалтыратса әйбәт булыр иде, телефондагы балансым тагын да өскә менәр иде. Бүреләр арасында бүре булып уламыйча башка чара юк».

Александр АЛЁШИН



# Машина-тамаша




## ЮЛ ЧИТЕННӘН ХӘБӘРЛӘР

Башкортстанда гадәти булмаган юл вакыйгасы булган. Анда сыра төялгән фура әйләнгән. Каты бәрелүдән кузов ачылып киткән, һәм сыра банкалары юлга таралган. Җирле халык, югалып калмыйча, кадерле эчемекне өйләренә ташып бетергән.

Автосөючеләр өчен яңалык! Алексеевский – Әлмәт түләүле трассасыннан үтү (145 километр) 3335 сумга төшәчәк. Бу бәя шулкадәр чиктән ашкан ки, хәтта трассаның инвесторы кискен рәвештә каршы чыккан һәм хәзер рәсми протест әзерли. "Бар генә аек фикер йөртүче кеше дә юлдан үткән өчен мондый акча түләмәячәк. Чик белергә кирәк!" – дип белдергән "Нефтегаз" эшмәкәрлек субъектына нигез салучы Фоат Комаров.

Чаллыда күп квартиралы йортны төзүче графика редакторы мөмкинлекләреннән оста итеп файдаланган. Территорияне чисталыкта тоту өчен җаваплы буларак, ул район хакимиятенә Шамил Усманов урамын төзелеш пычрагыннан чистарту турында отчёт җибәргән. Дөрес, фотодагы трактор йортлар сурәте өстенә "фотошоп" ярдәмендә куелган булган. Шул ук вакытта чистарту эшләре чынлап та башкарылган булган, фоторәсемен генә ясарга өлгермәгәннәр.

Яңа реккорд! Казанда юл инспекторлары 22 яшьлек кайнар канлы иномарка йөртүчене тоткарлаганнар. Машинасын бер атна элек кенә учётка куюга карамастан, аның инде 326 (!) штраф җыярга өлгергәнлеге ачыкланган.







Вячеслав ШИЛОВ

## СҮЗ ИЯРӘ – СҮЗ

"Бөке" – ул бер урындагы юләрләр һәм юллар.

Икътисадый үсешне бензинга бәяләр күтәрелү буенча күзәтеп була.

Права ал да "бөке"дәге үз урыныңа кереп утыр.

Автобуслар әкрен йөри, дип зарланган кешенең беркайчан да аның артыннан чапканы юк.

Юл аркылы чыкканда – һәрвакыт җәяүле хаклы. Исән булса, әлбәттә.

Тәҗрибәле йөртүче һәрвакыт үз машинасының алдыннан барган машинаның алдыннан машинаны күзәтә.

Безнең кешеләр җир асты кичүеннән бик кирәк булганда гына файдалана.




## КРИМИНАЛЬ ПОЛИЦИЯ

Моннан соң җинаять эше капланган кешеләр Эчке эшләр министрлыгында, Федераль җәзаларны үтәү хезмәтендә һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында эшли алачак. Дөрес, бу авыр җинаять буенча утырганнарга кагылмый, инновация кечкенә җинаятьләрдә хөкем ителгәннәргә генә кагыла. Бу карар персонал җитмәү сәбәпле кабул ителгән. Мәсәлән, бүген Эчке эшләр министрлыгында кадрлар кытлыгы 174 мең кеше. Аз хезмәт хакы, озак эш вакыты, төнге смена полиция хезмәткәре һөнәренә җәлеп итми торган сәбәпләр. Ләкин законны бозган кешеләр аны ашкынып яклый алырлармы – бу төп сорау.

## ТЕГҮЧЕ, УРАКЧЫ
## ҺӘМ МАШИНА ЙӨРТҮЧЕ

Тюменда "тәгәрмәчле фельдшер" эксперименты ярдәмендә ашыгыч медицина хезмәтендә машина йөртүче персоналының кытлыгын чишәргә тырышалар. Хәзер команда ике фельдшердан торачак, берсе пациентны күзәтә, икенчесе рульне бора. Әгәр дә машина йөртүчегә машинадан чыгарга тыелса, пациентны ничек аңга китерүне вакыт күрсәтәчәк. "Үз үзеңә фельдшер" эксперименты гына башланмасын.


## ФӘН ҺӘМ ТОРМЫШ


Иркутскта өч дистә фән кандидатларына һәм мактаулы укытучыларга һөнәрләрен үзгәртергә тәкъдим иткәннәр. Мәгариф үсеше институты җитәкчелеге, башка институт белән кушылгач, реструктуризация ясаган һәм персоналны кыскарту эшләрен башкарган. Мондый очракларда гадәттәгечә берничә кафедра бетерелгән, ә җитәкчеләргә, методистларга, доцентларга һәм укытучыларга кирәкле эшчеләр исемлеге (сатып алу белгечләре, эшчеләр, җыештыручылар һәм кием алып торучы) белән хатлар җибәрелгән.

## ШӘХСИ ЭШ

Губернатор боерыгы буенча, Самара түрәләрен хәзер регуляр рәвештә детектор белән тикшереп торачаклар. План буенча – ярты елга бер мәртәбә һәм планнан тыш коррупциядә шик булган очракта. Дөрес, алар полиграф белән очрашуның ирекле булачагын һәм эш сорауларына гына кагылуларын ачыклаганнар, белгечләр шәхси тормышларына катнашмаячаклар. Ләкин детекторны үтәргә теләмәгәндә нәрсә булачагы әлегә аңлашылмый. Элеккеге губернаторның түрәләрне наркотикларга тикшерү инициативасы алга китеш тапмаган.

## РӘССАМ СӘХИФӘСЕ







Вячеслава ШИЛОВ рәсемнәре







## ЯСАЛМА АВЫРУЛАР

Билгеле булганча, матур булу корбанлык һәм акча таләп итә. Казанда эшләүче косметология клиникаларының берсендә клиентлар моны үз күзләре белән күргән. Пациентларның төп проблемаларын хәл иткәннән соң косметологлар бөтен организмга түләүсез диагностика тәкъдим иткәннәр. Тулысынча сәламәт кешеләр булмый, әлбәттә – тикшерелеп бетмәгәннәр була. Шуннан соң һәр клиентның сәламәтлегендә зур акча таләп итә торган җитди проблемалар "тапкан" докторлар. Ә "Авыру"лар, клиентлар барысына да риза булган көтелмәгән барлыкка килгән бу мәсьәләләрне хәл итү өчен, акчалары җитмәгән очракта кредит алуга да барганнар. Аферист косметологлар гражданнарны бик оста эшкәрткән – 50 кешедән 50 миллион сум суырып чыгарганнар. Ә бу нәкъ "Аеруча зур күләмдәге мошенниклык" статьясына туры килә.

Никифор ТУКМАЧЁВ

## ЭЛЕК һӘМ ХӘЗЕР

Элек табиб әйтми иде
Яман чирләр тапса да.
Күңелне юата иде,
Санаулы көн калса да.

Хәзер булмаган чирне дә
Бар дию кулайрак.
Чөнки булмаган чирләрдән
"Дәвалау" файдалырак.

## ЯХШЫ СҮЗ

Табиб тыңлап карады да,
Бабай, ди, ничә яшьтә?
Быел әле үлмисең, ди,
Яшә, курыкмый яшә.

Кош тоткандай өйгә кайтсам,
Менә сиңа тамаша.
Декабрьнең утыз бере –
Бу ел беткән ләбаса.

Никифор ТУКМАЧЁВ

## ТАБИБТА


Әйдә, бабай, сөйләп җибәр
Нәрсә борчый, ник килдең?
Чирләрем күп, тик барсын да
Сөйләр акчам юк минем.
Компьютерда казынды да
Бер өч юллама бирде.
Шушы анализлар белән
Тагын килерсең, диде.

Анализ җыеп унбиш көн,
Әзер булгач та килдем.
Кардиограммам юк икән,
Үтмәгәнмен рентген.

Анализны карамый да,
Компьютерда казына.
Доктордан чыгып качмыйча
Түзеп торам аз гына.

Барсы да синең әйбәт, ди.
Түзәрлек, ди әлегә. Менә
Гаҗәп, барсы әйбәт,
Начар минем хәл генә.









## ӘЗ-МӘЗ РИШВӘТ ТУРЫНДА...

Намуслы түрәләрне хәзер ришвәт түләп тә табып булмый.

**Ришвәтче ул самолёт кебек – утыртмыйча туктамый.**

Барысы да – закон кысаларында. Ә кысалар һәркемнең үзенеке.

**Коррупция белән көрәш көрәш өстеннән тулысынча җиңүгә кадәр дәвам итә.**

Бездә коррупция – эшмәкәрлекнең бердәнбер табыш китерә торган төре.

**Бүген алалар, иртәгә сорыйлар, берсекөнгә таләп итәләр.**

Иң шәп кесә караклары дәүләт кесәсен чистарта.




• • •

Ни өчен бәяләрне күтәреп булмастай дип әйтәләр? Югыйсә аларны рәхәтләнеп күтәрәләр бит. Көн саен...

• • •

Ире хатынына шалтырата:
– Син кайда?
– Мәңгелек ут янында.
– Парктагымы?
– Юк, кухняда ашарга әзерлим.

• • •

Баласына дәресләрен хәзерләргә булышканнан соң, әтисе аңлаган, улыул укыган мәктәптә укытырга мөмкин.

• • •

Нәбиуллина, инфляция ни өчен арта, дип исәпли, чөнки кешеләрнең акчасы бик күп, шуңа күрә даими норманы (ключевая ставка) арттырырга кирәк, дип карар кыла. Бәлки, ул ниһаять шул кешеләрнең исем-фамилияләрен әйтер?

• • •

– Әйтерсең лә минем токымда шаманнар булган кебек.
– Нигә шулай уйлыйсың?
–Һәрвакыт кемне дә булса барабанга суккан кебек төеп аласым килә...

• • •

– 90-60-90, 120 гә 80, 3 мәртәбә 100. Барысы да аңлашыла бит, әйеме? Ә үзегез математиканы яратмыйм дисез.

• • •

– Хәзер яшьләр бөтенләй томана. Ёж сүзендә дүрт ялгыш!
– Ничек шулай булырга мөмкин? Анда бит болай да өч кенә хәреф...

• • •

Нигә рус менталитетына ят сүз – “бизнесвумен” кулланырга? Гади һәм аңлаешлы итеп “деловая колбаса” дисәң булмыймы?

• • •

– Булды! Сишәмбедән яңа тормыш башлыйм!
– Ә нигә дүшәмбедән түгел?
– Ну, дүшәмбедәге тормыш нинди инде ул...







## КАЧЫШЛЫ УЙНАУ

Өлкән буын кешеләре, хәзерге балаларның җан-тәннәре белән гаджетларга чумган, китап укымыйлар һәм ишегалды уеннары уйнамыйлар, дип лаф оралар. Ә полициядә исә башка фикердә торалар: ишегалды уеннарын алар ничек кенә уйныйлар әле – ләкин моны зурларча һәм закон кысаларыннан чыгып эшлиләр.

Мәсәлән, яшь буын олы абыйларга машиналар урларга ярдәм итә, мошенникларда курьер булып, ә наркомафия әһелләрендә таратучы булып эшлиләр. Соңгы ел эчендә генә синтетик наркотиклар тараткан өчен республикада 45 балигъ булмаган яшүсмер торкарланган. Мисал өчен, Әлмәттә 11 яшьлек малай наркотиклар таратып йөргәндә эләккән, ә Түбән Камада 13 яшьлек кызый "качышлы уйнаган" – шәһәр буенча шул зәһәр төрелгән төргәкләрне яшереп йөргән.

Хокук сакчылары, борчылып, "уйнаучы"ларның яше елдан-ел кимеп баруы турында белдерәләр. Эшләр болай барса, тиздән криминаль белешмәләргә балалар бакчасына йөрүчеләрнең дә эләгүе бик мөмкин. Бу хәлне үзгәртү максаты белән мәктәпләрдә тыелган матдәләр куллануны ачыклау өчен, көтелмәгән тикшерүләр уздыру планлаштырыла. Бу балаларны хәвефле "уенннар"дан туктатырмы, монысын вакыт күрсәтер.












Дамир МОРТАЗИН

# А һәм Б

Мәктәп кырыеннан үтеп барам. Тукталып калдым. Тәрәзәләренә карадым, ишегалдындагы бер төркем укучыларга – мине шикле уйлар биләп алды. Миңа кинәт оят булып китте: улым дүртенче сыйныфта укый бит, ә мин әле бер тапкыр да мәктәптә булганым юк һәм ничек укыганы белән кызыксынганым да булмады. Намусым пышылдап куйды: "Син хәтта улың Маратның тәртибен белергә дип җыелышларга да йөрмәдең, хатыныңа йөкләдең ул эшне. Кер, белеш, сөйләш, әти вазыйфасын үтә!"

Уйдан гына каршы килеп: "Нишләп бер тапкыр да булмаска?! Ә мәктәпкә иң беренче кем озатты? Ул "Б" классына билгеләнгән иде бугай. Мин укытучысына чәчәк бәйләме дә бүләк иттем! Мине исендә дә тотадыр әле..."

Шундук аякларым мәктәпкә юнәлде. Беренче ишек төбендә үк омон киемендәге каравылчы туктатты. Мин аңа килүемнең сәбәбен аңлаттым. Ул карашы белән мине тикшереп чыкты, документларымны карады, металлодетектор аркылы үткәрде һәм ниһаять ягымлыланды:

– Синең дүртенче "Б"ың икенче катта, укытучылары да шунда, тизрәк бар! – диде.

Шунда күтәрелеп, ишекләрен ачтым. "Кызык, ул мине таныр микән? Минем букетым бит иң кыйбатлысы иде..." – дип уйлап куйдым.

– Исәнмесез! Минем Маратым соңгы вакытларда бернинди дә начарлыклар эшләмәгәндер бит? – дидем.

– Әһә, ниһаять килдегезме! – дип, көрсенеп сүзен башлады укытучы. – Ничек шулай сез? Бер дә улыгызның хәлләре белән кызыксынмадыгыз, ә ул, әйтсәм әйтим, өйгә бирелгән эшләрен үтәми, дәрес вакытында уйнап утыра, башкаларга комачаулый – тәртибе бик начар! Әле күптән түгел генә глобус белән футбол уйнаган!

– Футбол инде ул – безнең гаиләбезнең канында... – дип әйтеп куйдым мин, борчылган сыман кыяфәт ясап.

– Мәктәптә кирәкми бит инде глобус белән! – диеп дәвам итте укытучы ризасызлыгын белдереп. – Ата-аналар җыелышында хатыныгызга күпме әйтергә була – улыгызны тәрбияләүгә тотынсын дип...

– Гафу итегез, эштән бушап булмый, командировкалар, ипотека, тегесе-монысы, – дип каушабрак калып ишеккә таба юнәлдем. – Гаеп бездә, күздән ычкындыргандыз, төзәтербез...

– Барыгыз һәм безнең сөйләшүебездән нәтиҗәләр ясагыз, – дигән сүзләре белән озатып калды укытучы.

"Ну кирәген бирәчәкмен мин аңа глобус белән футбол өчен!" – дип, Маратны кыйнардай булдым, өйгә кайтып җиткәндә.

– Улым, укулар ничек? – дигән хәл белешү сүзләрем атылып чыкты үзен күрү белән.

– Бүген тагын "биш"ле! – диде ул, көндәлеген сузып. – Укытучым мактап та алды!

Дневникның тышына карап катып калдым: анда минем улым – дүртенче "А" классында укучы дип язылган иде.

Хатыныма шул булган хәл турында сөйләгән идем, көлүеннән туктый алмый газапланды, ә соңыннан кайчагында шундый туры килүләр турындагы кызык очраклар килеп чыгуын әйтте:

– Маратлар һәр класста бар икән. Җыелышларга әниләр генә йөри ди, укытучылар әтиләрен күргәннәре юк. Футбол белән барлык балалар да мавыга. Менә шуннан буталчык килеп чыккан. Ешрак мәктәпкә баргаларга кирәк, әткәсе! Барырсың берчак, ничек укыганын белергә, ә ул инде институт бетергән булып чыгар...

Альберт ГАДЕЛ

## ЛЕНИН БАКЧАСЫНА АРТЫ БЕЛӘН КЕРГӘН

Милләтебезнең иң оста гармунчысы, музыкант-шамакай, Татарстанның бер дигән атказанган артисты Гали ага Җәмлиханов турында күп кенә кызыклы мәзәкләр йөри иде. Ул үзе дә "гаҗәеп шәп" эстрада артисты, экспромтка һәвәс шәхес иде. Сүз остасы, Татарстанның атказанган артисты Әзәл ага Яһудин белән Гали ага икесе генә гастрольдә йөриләр.

Гали ага – фронтовик, сугышның башыннан азагына кадәр фронтта була.

1950 елның урталарында, гастрольдә, район кунакханәсендә ял итеп ятканда Гали абый Әзәл агага озак кына карап тора да әйтеп куя:

– Әзәл, мин сиңа карыйм да, исем китеп сокланып куям, безнең татарлар арасында да немец милләтенә охшаган кешеләр булыр икән, – ди.

Әзәл абый бик "четерекле" кеше иде. Гали абыйның әче телле булуын белеп, тәгәлрәк сөйләвен сорый:

– Ну-у, шуның белән нәрсә әйтмәкче буласың? – дип, чекерәеп карый.

– Менә, малай, валлаһи, син шулкадәр Рейх министры Геббельска охшагансың, әгәр киногa төшсәң, аерып алырлык булмас иде, – ди.

Әзәл ага – чын күңеленнән коммунист. Ленин әсәрләрен култык астына кыстырып филармониягә килә иде. Шундый кешегә шундый чагыштырма бирү, гафу ителмәслек түбәнсетү булып тоела.

Алар үзара бераз әйткәләшәләр дә, тынычланалар.

Гастрольдән кайтуга, Гали аганы "Черек күл"гә НКВДга чакырып повестка килә.

Репрессия шаукымы әле көчле чорлар булгач, Гали ага бераз шөлләп, хатыны, балалары белән саубуллашып, повесткасы белән паспортын алып НКВДга килә.

Аны подполковник кабул итә һәм Әзәл ага язган гаризаны укып чыга.

Гали ага түзми, шушы дорфа кәмиттән кычкырып көлә.

– Иптәш подполковник (татар кешесе, бүтән милләт кешесе булса, Алла белсен нәрсә килеп чыгасын) валлаһи менә, Әзәл Яһудин шулкадәр Гитлерның Рейх министры Геббельска охшаган бит, – дип көлүен дәвам итә. Шуннан соң алар икәүләшеп көлешәләр дә, Гали ага "телдән" кисәтү ала. Әзәл агадан гафу үтенергә сүз бирә. Шулай итеп ул җиңел генә НКВДдан котыла.

Филармониягә килгәч, баскычта сөйләшеп торган берничә артистлар арасында Әзәл аганы күреп гафу үтенә:

– Әзәл, җаныкаем, син һич тә Геббельска охшамагансың, гафу ит, ялгышканмын, ди дә китеп бара.

Гали абый филармониягә килгәч, артистлар аны уртада калдырып, хәлен аңлап, йомшак кына ни өчен чакыртуларын сорыйлар.

Гали ага бик борчулы, кайгылы күренеп:

– Әй туганнар, фәлән көнне, салган баштан, кызмача, Ленин бакчасына артым белән кергәнмен. Шуны НКВД хезмәткәрләре тәрәзә аша карап торганнар...

– Соң, шуннан, шуннан, Гали ага, ни булган? – дип, артистлар чынлап ышанып гаҗәпләнәләр.

– Менә шуның өчен чакыртып, моннан соң капкага алдың белән кер! – дип, каты кисәттеләр дип, урамга тәмәке көйрәтергә чыгып китә.




Иосиф БОБРОВИЦКИЙ, 1963 ел.




Иван ХАНТИМЕРОВ, 1964 ел.

– Рекорд булды бу!




• • •

Акча җыеп, яхшысын алыр өчен, 2019 елда машинаны саттык.

2024 елда 2019 елдагысын сатып алыр өчен акча җыйдык.

• • •

– Кадерлем, син көн саен чибәрләнәсең!

– Шулчаклы арттырма инде!

– Ярар, ну көнаралаш.

• • •

Автомобиль йөртүче күзәтүе: "Нигәдер ашыкканда барысы да өстерәлеп бара, ташбакалар диярсең, ә ашыкмыйча җайлап кына баргандa – бөтенесе дә шашкан кебек, машиналарын куалар".

• • •

Сезне бүген барысыннан да ныграк нәрсә борчый?

– Тук-тук, акча юк...

– Аңламыйм, юк нәрсә ничек борчырга тиеш?

• • •

Укытучы укучының әнисенә зарлана:

– Сезнең улыгыз географияне бөтенләй белми!

– Юкка хафаланасыз. Безнең хезмәт хакы белән әллә ни еракларга китеп булмас.

• • •

– Гаепләнүче, зәркән кибетен таларга нәрсә этәрде соң, ә?

– Витринада: "Мөмкинчелекне ычкындырмагыз!" дип язылган иде бит.

• • •

– Элек әкиятләр ничек башлана иде: элек, борын-борын заманда, яшәгән ди бер патша, ерак-ерак бер мәмләкәттә... Ә хәзер әкиятләр ничек башлана: экспертлар әйтүе буенча дип...

• • •

– Әйдәгез иртәгә имтиханга чәчәкләр белән киләбез?

– Әйдәгез торт белән?

– Әйдә акыл белән, укытучы шаккатсын әле!

• • •

Баланы кәбестәдән табу катлаулы түгел... Ә менә "кәбестәне" бала тәрбияләү өчен табу – зур мәсьәлә!




Сергей КОКАРЕВ

**Рөстәм ЗАРИПОВ**


*"Җаныңныңваклыгын сылтама заманга..."*

**Равил Фәйзуллин**

Җаның вак булганга заманны әрләмә,
Олуглык – авыр йөк ул рухи кәрләгә...
Ишмә бар гаепне Мәскәүгә, урыска,
Кемлегең күптән фаш, алдарга тырышма.

Җаныңның ваклыгын аударма халкыңа,
Ул әле һәр мизгел яшим дип талпына!..
Эзләнмә як-яктан, ул синең үзеңдә,
Ул синең күзеңдә, һәр әйткән сүзеңдә.

Ул ваклык һәр тамчы каныңда чагыла,
Миеңдә, рухыңда, күңелеңдә кагына;
Табигый казаныш җаныңның ваклыгы,
Вакланмый нишләсен, булмагач пакьлеге...



Максим СМАГИН




## ҖӘЯҮЛЕЛӘР КЕШЕ ТҮГЕЛ

Кадерле "Чаян". Ниһаять Казанда, реконструкцияләнеп, 27 миллиард сумга төшкән Горький шоссесы тәгәлләнде. Хәзер бернинди светофоры булмаган 11 километрлы юлның каршылыксыз үтү мөмкинлеге ике мәртәбә артты – автомобиль йөртүчеләрнең шатлыгын белсәгез! Ә менә җәяүле гражданарга бу рәхәтлек азрак тәтеде. Краснококшай урамындагы җәяүлеләр өчен чыгып йөрү мөмкинлеге бетте. Янәшәсендә генә автомобильләр өчен тукталышлары да бар иде. Шоссеның икенче ягында ике гимназия, балалар бакчасы, кибетләр, автобус тукталышлары калды. Ул якка эләгү өчен иң якын булган чыгу урыны бер километрга якын һәм кирегә килү дә шулхәтле – җәяүлеләр өчен уңайлыклар булдыру каралмаган. Җәяүлеләрнең бернинди хокуклары юк икәнлеге ап-ачык, димәк алар кеше түгел.

**М. ИБРАҺИМОВА**

КАЗАН

## ҖАВАПЛЫЛАР ҖАВАПСЫЗ...


Хөрмәтле редакция! Әйтәләр бит: төзек канализация – цивилизациянең бер билгесе дип. Әгәр ул шулай икән, безгә, Константиновка бистәсендә яшәүчеләргә, цивилизациягә бик ерак икән әле. Менә инде ничә еллар буе бистә буйлап әшәке ис таратып ташкын сулар ага. Аларның су башы төрле җирдән – әле аннан, әле моннан канализация бәреп чыга. Ремонт ясап китәләр, яртышар гасыр яткан торбаларны ямап кына бетереп булмый шул, алар инде череп беткән. Аккан сулардан күлләр барлыкка килеп, үзенчәлекле экосистема ясала. Зарланып шикаятьләр язып карыйбыз, ел саен һаман шул бер җавап алабыз – торбалар алыштырырга акча юк һәм алдагы елларда да күренми диган. Дөрес, ул сазлык ясалган җирләрне туфрак белән күмеп торалар, ләкин су үз юлын барыбер таба бит – җаваплы кешеләр кебек түгел.


**Константиновка бистәсендә яшәүчеләр**

КАЗАН, Интернационал урамы

**ЧАЯНнан.** Номерны әзерләгән арада, җәяүлеләр өчен кечү юлын ачканнары мәгълүм булды.





*Шәйхи Маннур (Шәйхелислам Фәрхулла улы Маннуров) 1905 елның 15 гыйнварында элекке Казан губернасы Мамадыш өязе (хәзерге Татарстанның Мамадыш районы) Тулбай авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Шундагы һәм күрше Шәмәк авылындагы мәдрәсәләрдә башлангыч белем ала, Октябрь революциясеннән соң Шәмәктә ачылган «икенче баскыч эш мәктәбе»ндә һәм Мамадыштагы педагогия курсларында укый. 1921 елгы ачлыкта аның әтисе бөтен гаиләсен алып, Кузбасстагы Анжерка-Судженка шахталарына килә. Анда уналты яшьлек Шәйхинең хезмәт юлы башлана. Ул шахталарда кара эшче, укытучы булып эшли.*

*1923 елдан ул төрле уку йортларында белем ала, Тобол, Урал, Новосибирск якларында культура-агарту, матбугат эшләрендә эшли. 1927–1929 елларда армия хезмәтендә була, аннан кайткач, 1932 елга кадәр Донбасста эшче-прокатчы, укытучы-ликбезчы, Днепрогэста бетончы булып эшли. Бу елларда ул үзенең шигъри әсәрләрен иҗат итә, китаплар бастыра. Соңрак Мәскәүгә килеп, берникадәр вакыт газетада эшләгәч, Казанга кайта һәм 1933–1937 елларда педагогия институтында укый. Шуннан соң ул бер ел «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналының җаваплы секретаре булып эшли дә, 1938 елдан Ватан сугышына кадәр әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә. 1934 елда шагыйрь СССР Язучылар союзына алына.*

*Сугышның беренче көннәреннән үк Ш. Маннур үзе теләп фронтка китә, анда төрле фронт газеталарында хезмәт итә. Сугыштан соң Татар дәүләт опера һәм балет театрында әдәби бүлек мөдире булып тора һәм 1948 елдан гомеренең соңгы көннәренә кадәр профессиональ язучы була.*

*Әдәби хезмәтләре һәм Ватан сугышындагы батырлыклары өчен Шәйхи Маннур Хезмәт Кызыл Байрагы (1939), Кызыл Йолдыз (1945), «Почет Билгесе» (1957), Халыклар дуслыгы (1975) орденнары һәм берничә медаль белән бүләкләнә.*

*Шагыйрь 1980 елның 10 июнендә Казанда вафат була.*

*Шәйхи Маннурның иҗаты татар совет әдәбиятында күренекле урын тота. Поэзиядән тыш, ул проза өлкәсендә дә актив эшли.*

## ЯЛ МИНУТЛАРЫНДА

Землянкадан гармонь тавышы
Һәм җыр моңы тарала.
Сугышчылар ял итәләр
Сугыш тынган арада!
"Җырлыйк әле, ял булсын,
Күңелләр бер ачылсын.
Тиздән тагын кузгалырбыз,
Башлар гына исән-сау булсын".
Җырлый алар сузып-сузып,
Бер дәртләнеп-талпынып,
Бер елмаеп, бер моңаеп –
Сөйгәннәрен сагынып:
"Шушы матур кичләрдә,
Йомшак карлар төшкәндә,
Уйлый микән җаныем мине,
Көтә микән, күреп төшләрдә..."
Сызыла гармонь,түгелә бар моң,
"Төтен шәм" яктысында –
Ял итә батыр егетләр
Тимер мич каршысында.
"Ян, учаккай, ялкынлан,
Сакла безне салкыннан.
Салкында да, ялкында да
Без куабыз дошман артыннан".

## БЕЗНЕҢ КЫЗЛАР

Явыз үлем Сездән куркып торсын,
Дошман уклар читләп үтсеннәр,
Иң куркыныч хәлдә калганда да
Бу җырларым саклап йөртсеннәр.
Йөрәгемнең сүнмәс ялкыннары,
Хисләремнең якты язлары,
Җырларымның иң-иң матурлары –
Сезгә булсын, татар кызлары!
Чал башымны иеп сезнең алда,
Хөрмәт белән карыйм мин сезгә.
Халкыбызның данын һәм намусын
Сез йөртәсез саклап үзегездә.
Күпне күргән карт әниләр безнең
Үстергәннәр сезне кадерләп,
Сыгылмас һәм сабыр сыйфат биреп,
Көн итүне яхшы хәтерләп.
Сез йөрисез үлем кырларында
Чын сугышчы егет шикелле,
Мәхәббәт һәм шәфкать белән безгә,
Сез җиңәсез шыксыз үлемне.
Сугышларда безне саклар өчен
Ут эченә барып керәсез.
Кирәк чакта, һичбер кызганмыйча, –
Гомрегезне, хәтта, бирәсез.
Гөлләр түшим йөргән юлыгызга,
Алар сезгә юлдаш булсыннар.
Чын күңелдән бәхет, шатлык телим,
Көннәрегез матур узсыннар.

## БӘЛКИ СИН ДӘ СӨЯРСЕҢ...

*Җәүдәт Фәйзи көе*

Күктә якты-якты йолдызлар күп,
Иң яктысы син күк тиясең.
Җирдә матур-матур чәчәк бик күп,
Килә сиңа өзеп,
Килә сиңа өзеп бирәсем.

Эчтә тулып-тулып хисләр ята,
Телим сиңа әйтеп бирергә.
Хәзер әйтәм, әйтәм дигән чакта,
Тотлыгам да китәм,
Тотлыгам да китәм кирегә.

Күктә якты-якты йолдыз яна,
Иң яктысы син күк тиясең.
Сине уйлый-уйлый мин юанам,
Бәлки әле син дә...
Бәлки әле син дә сөярсең...

## «НАЧАР» СҮЗ

*(Шаян парча)*

Ап-ак йөзле, зәңгәр күзле
Кечкенә бер кыз бала,
Чыксам урамга, һәр көнне:
«Бабай!» «Бабай!» – дип кала.

Әй ачуым килә шуңар.
Каннарым кайный хәтта.
Башта дәшми йөрдем моңар,
Янәсе, минем хакта
Түгел бу сүз... Башка бер карт
Узадыр бу тирәдән.

Бу кыз, ахры, шуңа кат-кат
Кычкырырга өйрәнгән...

Үзем карыйм як-ягымны,
Басып киям бүркемне:
«Бу яман күз чәч агымны
Күрмәсен, дим, һәр көнне!..»

Ләкин бар да тиккә генә,
Теге матур кыз бала
Һаман шулай читтән генә:
«Бабай!» «Бабай!» – дип кала.

Тагын ярсыйм: «Әллә моның
Әнкәсе диванамы?
Шундый начар сүзгә кызын
Өйрәтеп чыгарамы?..»

Әйттем кысып өч тешемне:
«Ялгышасың, сабый! – дим, –
Аермыйсың син кешене:
Бабай түгел! А-бый!» – дим,

«һе-һе-һе! – дип көлә ул кыз, –
Алдама син алай! – ди. –
Күптән инде белә бу кыз:
Син бит Маннул бабай!» – ди.

Юк, килешмим! Риза түгел!
Нинди «бабай» булыйм мин?
Әле яшь-яшь минем күңел!
(...Уф... йөрәгем...
Нигә авыр сулыйм мин?..)

Нәрсә булган инде, бала,
Үртәмәсәң мине бик?
«Абый!» диеп калсаң кана,
Конфет бирер идем бит!

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

# Күңелле яшиләр

Көн саен диярлек, эштән кайткан вакытта, подъезд янында күрше апалар-әбиләр утыра. Нәрсә сөйләшәләрдер?

Бер көнне шулай яннарыннан узып барганда, мине туктаттылар да:

– Карале, күрше, ник исәнләшеп кенә үтәсең безнең яннан? Бераз ял ит, сөйләшеп утырыйк. Эштән кайтып килүеңме? – диләр.

– Әйе. Эштән кайтам. Кибеткә дә кердем кайтышлый.

– Кибет дигәннән, – дип башлады берсе, – бигрәк тә бәяләр үзгәреп тора инде. Иртән керсәң – бер бәя, кичен – икенче.

– Иртән бер бәя булмыйча, син пенсионер бит. Шуңа арзанракка аласың, – дип, сүзгә икенчесе кушылды.

– Аннан әйтүем түгел. Менә, мәсәлән, литр ярымлы суны мин, акция буенча дип язылгач, кырык биш сумнан ала идем. Кичә керсәм, шулай ук акция дип язылган, ә бәясе сиксән сумга күтәрелгән. Бу нинди эш тагын?

– Бар инде андый хәлләр, булгалый. Ә менә мин, – дип башлады өченче күршем, – песиебезгә каймак алам.

– Бигрәк иркә икән мәчегез. Каймак кына ашатасың, – диде апалар.

– Нишлисең? Балалар өйрәтте каймакка. Хәзер үзләре алмый, песине ашатырга миңа калды. Нәрсәдән башладым әле сүземне? – дип исенә төшерергә тырышты өченче күршем. – Ә, әйе, шуны әйтәсе идем, каймакның да бер эшмәкәрнекен генә ярата. Анысын да әле кайчагында ашый, кайчагында юк. Ник ашамыйдыр? Башта килеп иснәп карый. Ярыйсы булса, ашый.

– Ник ашамаганы билгеле – дөрес каймак түгел ләбаса! Без бит песи түгел, аермасын сизмибез, безгә барысы да бара.

– Әй, ярар, күршеләр, әйдәгез бәяләр турында сөйләшмик әле. Бераз күңеллерәк нәрсәләр сөйләшик. – дип кушылдым мин.


– Әйе, күңеллесе шул, – дип куйды икенче күршем. – Минем озакламый туган көнем җитә. Балалар: "Әни, сиңа нәрсә бүләк итик?" – дип сорадылар. Мин әйтәм, чәшке тун кирәк, шуны бүләк итегез, дидем.

– Ул тун нәрсәгә кирәк сиңа? Аны киеп кая барасың? Өлкән яшеңдә. Җитмештән арттың түгелме соң?

– Ничек нәрсәгә? Шифаханәгә йөрергә!

Барыбыз да көлешеп куйдык.

Менә шундый инде безнең күршеләр. Зарланалар да, көлешәләр дә. Күңелле яшиләр!



Ринат АБЗАЛОВ

Хәмид ВӘЛИДИ

## ӘБИЛӘР ЗАРЫ...


Күрешкәндә, белешкәндә,
Әбиләр гел зарлана:
– Колаклар сукмый башлады,
– Күзләр, дип, начарлана.
Түгелдер аларның, әмма
Бу – күңел – аһ-зарлары.
Тел төбендә була, төптә,
Һәр зарның да зурлары.
– Мосафир, дип, әйткәнемне,
Әфисәр, дип, аңлапмы,
Туксанын тутырган әби,
Зарын болай аңлатты.
– Мин яшь килен чакта, улым,
Урәтникны бер күреп,
Узган идем яннарыннан,
Каш уйнатып, бер көлеп.
Житте шул озак елларга,
Белмәдек "чирекле"не.
Исән калды тавыклар да,
Суймадык "кикрикле"не.
Бүген менә шуфер егет,
Утын китерә икән,
Әбәзәтелне аңарга
Тулы бер ярты иртән.
Йәнә дә тракторчыга,
Бакчаңны сөреп чыкса,
Аңа да куй бер яртыны
Икенче сөрми, юкса.
Йомгактай сарык тәкәсен,
Бер карап, печкән өчен,
Бөтен тавык, тагын ярты,
Мал врачына кичен.
Болай әйбәт мантюр малай
Тик ул да куймый кимен.
Табып булмый инде шунсыз,
Ул көйсез мантюр көен.
Белешмә өчен секлетарьга,
Бригадирга – азмы соң,
Әйтерсең лә мин яшергән,
Ул – "Әндри казнасы"н.
Сиңа гына әйтүем бу,
Аена алам ун ярты.
Житмәсә, шуның – төссезнең,
Тагын бәясе артты.
"Урядник" – дип, белде әллә,
И, сукыранды әби.
Туксаннан узган әбиләр,
Кайчак сөйли әллә ни.


**ЧАЯН**
**САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ**
1923 елдан чыга.
**№ 1 (1950) гыйнвар 2025**
Баш редактор: Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рассам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
420047, Татарстан Республикасы, Казан, Академическая урамы, 2
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

**Язылу индекслары:**
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.
Чыгу көне: 01.01.2025 ел.
Тираж – 1714 Заказ М-0004
**Редакциянең адресы: 420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.**
Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле
16+

# Уйна да, уйла да!




Ринат АБЗАЛОВ төзеде.




**1.** Тормыштан уңдым дип кайчан әйтеп була?

**2.** Ни өчен ир-атны кызып китү хәленә җиткермәскә?

**3.** Фикерне тиз генә нәрсә үзгәртә ала?

**4.** Иреңне башкалар белән бүлешмәс өчен, нишләргә кирәк?

**5.** Нинди мизгелдән соң Яңа ел яңа булудан туктый?

**6.** Кемнең аяныч көннәре елга ике мәртәбә?

**7.** Кем ул хирург?

## ҖАВАПЛАР

1. Күп нәрсәне онытырга яраган чакта. 2. Ул парга әйләнергә мөмкин. 3. Маңгаена китереп сугу. 4. Тураклагыз аны. 5. Оливье салаты беткәч. 6. Студентларның. 7. Яхшы коралланган терапевт.

**Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.**

Чайнвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 12 нче санында басылган чайнвордның тикшерү сүзе – **«УТЫР ӘЛЕ ЯННАРЫМА».**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

**Р. МОГЫЙНОВА** (Биектау),
**Н. ЙОСЫПОВА** (Арча р-ны, Яңа Кишет ав.),
**С. ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ** (Казан).

Җиңүчебез – Казаннан

**Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ!**

# Александр ШУЛЬПИНОВ



Ике уку йорты тәмамлап, инженер-техник һәм сәнгать белеме алып, Александр барыбер карикатурачы булып китә. 1984 елдан бирле ул «Чаян»ның даими рәссамы һәм темалар авторы. Өстәвенә, ул Россия һәм халыкара конкурс һәм карикатура күргәзмәләре дипломанты. Россиянең Рәссамнар берлеге әгъзасы. Башка рәссамнардан үткен темалары һәм үзенчәлекле графикасы белән аерылып тора. Безнең журнал битләрендә күпме вернисажы басылып чыкканнын Александр үзе дә хәтерләмидер... Бүген ул укучыларыбызга чираттагы күргәзмәсен тәкъдим итә.












4 612750 670080